Безнең белән үткән балачак кк үңелегездә мәңге калачак!

№41 (1167)
31 май
2007 ел

Кәмеш кыңгырау

Чаллы шәһәре ❄ Балалар һәм яшүсмерләр газетасы

1 июнь – Балаларны Халыкара яклау көне

Рәхәтләнеп биедем

Мин шәһәребезнең хореография мәктәбенә – "Сәйлән" бию ансамбленә бик яратып йөрим. Без анда халкыбызның төрле биюләрен һәм башка халыкларның биюләрен өйрәнәбез. Бәйрәмнәрдә чыгышлар ясыйбыз.

Мин "Сәйлән"гә 12 яшь тулу тантанасында катнашып, төп рольдә бал корты биюен башкардым. Энергетик мәдәният сараендагы отчет концертында халкыбызның "Чабата" һәм башкорт биюен башкардым.

Ләйсән ХӨЙРЕТДИНОВА,
73нче мәктәп, 1 "А" сыйныфы.

Һәркемнең үз балачагы



"Тор, кызым, тор инде, матур кызлар таң суыннан кайта торгандыр инде" дигән сүзләре белән уята иде мине балачакта әбием. Без аның белән көянтә-чиләк күтәреп, таң суына барабыз. Әле иртә, бик иртә. Салкынча җил исә. Чәчләремне тузгыта, битләремнән сыйпый, иркәли, назлый. Рәхәт иртә. Елга өстендә сөт кебек томан таралыргамы, таралмаскамы дип уйга талган. Яшел чирәм өстендә чык тамчылары җемелди. Әкрен генә кояш чыга. Елганың теге башындагы урман, тереклек уяна башлый.

Менә кояш та тулысынча нурын сибә башлады. Авылым уяна, тырышып-тырышып әтәчләр кычкыра, көтү китә. Үрдәкказ бәбкәләрен әбиләр-апалар болынга төшерәләр. Кырларда тракторлар гүләве ишетелә, авыр хезмәт көне башлана. Авыл уяна, шул авылымдагы хезмәт сөючә авылдашларымны мактап, тургай җырлап туя алмый.

Мин бик-бик яратам авылымның иртә таңнарын. Шул иртә таңнарда Зөһрә аланыннан җыйган җиләк тәмнәрен, әбием белән Камал марталындагы чишмәдән эчкән иртәнге саф суларының йомшаклыгын, Ташлы елга яры буендагы мәтрүшкәләрнең хуш исләрен оныта алмам инде беркайчан да. Кайда гына булсам да, әбием яшәгән авылымның иртә таңнарын сагынып, ашыга-ашыга кайтырмын, Алла боерса.

Эльза ГАЗИЗОВА,
КДУ филиалының II курс студенты.

Газетабызга язылу бәяләре: Чаллыда, Тукай, Әгерҗе, Актаныш, Мөслим, Минзәлә районнарында яшәүчеләр 00015 индексы буенча 114 сум 54 тиен түләп языла алалар. Башка шәһәрләр һәм районнар өчен: индекс – 31700, бәя – 144 сум 60 тиен.

Баш мөхәррир сүзе

Начар мультфильмнар

алар балаларны яхшыга өйрәтә аламы соң?!

Игътибар иткәнегез бармы: "Америка мультфильмнары"ның барысында да диярлек хәзинә эзлиләр. Кайчакта табалар да. Ә хәзинә табып килгән байлык — эшләп тапкан мал түгел ул. Димәк, мондый мультфильм эшләп, көч куеп көн күрергә түгел, «җиңел юл» белән байлык эзләргә өйрәтә.

Уолт Дисней мультфильмнарындагы принциплар: «егылып баручыны катырак эт», «кем егылган — шуны кыйна», "бар кешеләр дә начарлар". Америка мультфильмнарындагы геройлар нишлиләр? Иң беренче алар күңел ачалар. "Кара плащ" дип исемләнгән мультсериалны искә алыгыз әле. Анда кем дә булса эшлиме? Юк, барысы да иртәдән кичкә кадәр күңел ачалар. "Күңелле" булсын өчен кеше дә үтерәләр хәтта!

Аннан соң бу мультфильмнарда бер дә кеше кешегә дус һәм туган түгел. Ул аның конкуренты, көндәше, дошманы. Ә бит көндәшне юк итәргә, җиңәргә, һич югында мәсхәрә итеп көлкегә калдырырга кирәк! Шулай булгач, әлеге мультфильмнарны кешелекле, әйбәт булырга өйрәтәләр дип буламы?!

Юксыну, сагыш һәм моңсулык белән "совет" мультфильмнарын искә алабыз. Алар өмет һәм шәфкатьлелек белән сугарылган иде...

Хәзер Америка уенчыкларын тикшерик әле. Безнең илдә, курчаклар, игътибар итсәгез, барысы да "бәби". Аларны "ашатырга", "юарга", "киендерергә", арбасына салып йөртергә кирәк. "Бәби" — курчаклар нәни кызларны рәхимле, игътибарлы әни булырга, башкалар турында кайгыртырга өйрәтә.

Ә инде "үсеп җиткән" ялтыравык күлмәкләр кигән көяз Барби нигә өйрәтә? Аны киендерергә, өен җыештырырга һ. б. эшләргә кирәк — димәк, хезмәтче ролен үтәргә. Яисә Барбиның үзе кебек гел матур киемнәр алыштырып кына яшәүче байбикә булырга. Ябык һәм нечкә Барби — сау-сәламәт кеше шундый кыяфәттә була аламы соң? Ә бит Барбига охшарга тырышып тулы бер буын үсеп җитте...

Барби әле, кем әйтмешли, түзәрлек... Скелетлар һәм вампирлар, тимер тәнле генә түгел, тимер җанлы да булып кеше үтерүдә ярышкан роботлар, ерткычларга охшаган солдатлар. Сугыш, димәк, үтерү өчен техника... Болар белән уйнап үскән балалар кемнәр булыр?! Безгә сабыйларны Америка мультфильмнарыннан һәм уенчыкларыннан якларга да вакыт җитмәдеме икән?!

Җир шарында гаҗәеп балалар туу артканнан-арта бара. Франциядә аларны "тефлон", Англиядә – "меңъеллык балалары" дип йөртәләр. "Индиго", «миләүшә төсендәге балалар» дигән исемнәре дә бар. Алга киткән бай илләрдә мондый балаларга аеруча зур игътибар бирелә. Бездә, кызганычка каршы, сәерләр, хәтта авыру дигән караш яши килде. Ниһаять, илебездә дәүләт дәрәҗәсендә сәләтле балаларга ярдәм күрсәтү йөзеннән дәүләт – җәмгыять проекты әзерләнә башланды.

Магнит - балалар

Берничә ел элек Россиянең төрле төбәкләреннән магнит — балалар турында хәбәрләр ишетелә башлады. Мәсәлән, Түбән Новгородтан 14 яшьлек Маша Епифанова . Ул сәгатьләр буе тәненә калак, чәнечке (дуслары сораганда) тагып йөри ала. Машага акчалар да ябыша. Ә иптәш кызы Таня Свиринаның тәненә кәстрүл капкачлары да ябыша. Саратовтан Коля Тенькаев тәненнән хәтта үтүкләр дә "егылып" төшми. Анна Зверевага (Новосибирск) 12 яшь кенә булуына карамастан, авыр-авыр әйберләрне кулы белән дә, аяк табаннары белән тартып китерә. 10 яшьлек мәскәүле Кристина Гюларян кечкенә учларына калын журналларны да ябыштырып тотып тора.

Галимнәр әйтүенчә, соңгы елларда "магнит" — сәләтле балалар саны бермә-бер артты. Ә мондый балалар иң күбе 90нчы еллар уртасында туган. Галимнәр моның сәбәпләрен төгәл генә аңлата алмыйлар. Табиблар җитмәсә аларга "сәер" дигән диагноз да тагарга мөмкиннәр.

Индиго–балалар көне дөньяда 29нчы гыйнварда билгеләп үтелә.

Дөньяга яңа кавем килә!

шулай дип әйтергә тулы нигез бар

Сәләтлеме, әллә?!..

Могҗиза малай – Булат Хөсәенов Казаннан. 10 айлык чагында йөзгә кадәр саный белә. Ике яшендә өч телдә – русча, татарча, инглизчә йөзгә кадәр саный. Ожегов сүзлеген яратып актара. Балалар бакчасына аны 1 яшьтә 10 айда бирәләр. Тәрбиячеләр аның Шаинский җырларын көйләп ятуын ишетеп, шаккаталар. Ә бер тапкыр төшке аштан соң, "ите юк" дигән язу биреп тагын бер кат тәрбиячеләрнең һушын ала.

1 яшьтә 8 айлык чагында ук Булатның искиткеч хәтерле икәнлеге ачыла. Әнисе аңа Агния Барто шигырьләрен укый. Берникадәр вакыт үткәннән соң, әнисе тагын шул ук китапны алып укырга әзерләнгәндә, Булат яттан Барто шигырьләрен сөйләп бирә. Беренче сыйныфка барыр вакыт җиткәч, табиблар бу сәләтле малайны психиатрга исәпкә куярга тәкъдим итәләр, имеш, улыгыз бик үк тулы түгел...

Вундеркинд - миләүшәләр

Искиткеч сәләтле малай Павел Коноплев Мәскәүдә туган һәм үскән. 6 яшендә белгечләр анда үтә югары интеллектуаль сәләт ачалар. Бу малайны "иң югары сәләтле вундеркинд" дип атыйлар. Өч яшендә Павел йөгерек укый һәм көндәлек күңелдән катлаулы математик исәпләүләр чишә белә. Рәхәтләнеп әкиятләр һәм университет китаплары укый.

Алты яшендә Менделеев таблицасын «күрә» һәм аңлый. Пашаны аерым программа буенча укыталар, чөнки мәктәптә ул "ак карга" булып чыга: иң беренче алган билгесе ... "берле" була.

Әмма беренче сыйныфтан Паша дүртенчегә "сикерә" һәм "отличник"ка әйләнеп куя. 9 яшендә Плутон планетасы яктыртылышы турындагы мәсьәләне чишә. Малайның бу эшен академик Андрей Колмогоров (ул үзе дә, күрәсең, индиголар нәселеннән булгандыр – академик исеменә 39 яшендә лаек була) югары бәяли. 14 яшендә Паша компьютерларны математик тәэмин итү эшләрендә катнаша, 15 яшендә Мәскәү университетына укырга керә, аспирантура тәмамлый. Әмма табигать кешене югары акыл сәләте бирү белән беррәттән авырулардан саклый алмый. Павел да чирли башлый һәм нибары 27 яшендә, 2000 елны үлә.

Төньяк Осетиянең Змейская авылында күптән түгел тагын бер вундеркинд пәйда булды. 6 яшьлек Георгий Хинчагов берьюлы өч мәктәптә укый һәм барысында да укытучыларны математика, тел фәннәре буенча сәләте һәм искиткеч хәтере белән шаккатыра. Гриша бик җиңел генә үтә катлаулы математик мәсьәләләрне чишә, "җитди" гәҗитләр укый, яттан озын-озын поэмалар сөйли. Әтиәниләре аны Владикавказга, сәләтле балалар гына шөгыльләнә торган мәктәпкә йөртеп укыталар.

Гриша Наполеонга каршы

Зеленоград шәһәренең көчле фикерләү мәктәбендә 10 яшьлек "миләүшә малай" Наполеон Бонапартның сәясәтен тәнкыйтьләгән фәнни трактат язган.

1991 елны Бауман исемендәге Мәскәү университетына имтихансыз 12 яшьлек Алтай малае Эрнесто Евгений Санчес Шайда укырга керә. Соңрак ул берничә үтә кызыклы һәм кирәкле ачыш ясый. Эрнестодан 2 яшькә кечерәк Савелий Косенко шулай ук Бауман исемендәге университет студенты була. 2 яшендә Савелий укый белә, ә җиде яшендә үз компьютерында программалар төзи. Яшьтәшләренә караганда мәктәпне җиде ел алдан тәмамлый, 10 яшендә физикадан дәреслек яза. Савелийны Гиннесс рекордлары китабына язалар. Югары уку йортын ул 16 яшендә тәмамлый һәм берьюлы ике факультетта укый.

Пикассо яисә?..

Психологлар индиго–балалар бернәрсәдән дә курыкмыйлар, диләр. Максатларына ирешү өчен алар берни алдында да туктамыйлар. Алар икенче төрле, башкача "төзелгәннәр". Кызганычка каршы, Рәсәйдә сәләтле балаларны тәрбияләү һәм укытуның билгеле бер системасы булдырылмаган әле. Шушы теманы Мәскәүдә бары тик 2006 елны гына күтәреп чыктылар. Психологлар әйтүе буенча, индиголар аерым игътибар сорыйлар, чөнки аларга юнәлеш бирмәсәң, киләчәктә кем булулары билгесез. Галимнәр бертавыштан иң сәләтле балаларны кырыс шартларда тәрбияләргә киңәш итәләр. Дөньяда иң яхшы мәктәпләрнең берсендә – Англиядәге "Итон" көллиятендә – тәртип һәм уку шартлары үтә каттый һәм таләпчән.

Кадерсезләр

Жир йөзенә һәр сабый үз бәхете белән туа. Дөньяга килгәч, ул кайгыртуга, яратуга, гаилә җылысына, ата-ана назына мохтаҗ.

Ә бит кайбер әти–әниләр балаларына бөтенләй көн күрсәтмиләр, аларны тукмап, ачтан интектерәләр, урамга куып чыгарырга да күп сорамыйлар. Авыр сүзләр белән күңелләрен ялалыйлар. Балаларның өйдән китүләренә дә күп очракта ата-ана гаепле була. Йодрык астында изелеп яшәгәнче урамда ачлы-туклы яшәүне кулайрак күрәләр. Урамда да кырыс хакыйкать белән күзгә-күз очрашырга мәҗбүр була ул. Ашарга табу, ничек итеп булса да яшәргә тырышу өчен көрәшә башлый бала. Тамагын туйдыру өчен урлаша, тәмәке тарта, спиртлы эчемлекләр куллана башлый, аның җинаять юлына басу ихтималы да арта.

Комсомол районы Эчке эшләр идарәсенең балигъ булмаганнар белән эшләү инспекциясендә имин булмаган 130 дан артык гаилә теркәлгән. Шәһәребез буенча мондый гаиләдән булган балалар саны 2000 гә җитә. Һәм әлеге сан айлап түгел, көнләп арта бара. Эчкече ата-аналар арасында баласын мыскыллаган, кимсеткән, тукмаган өчен җәзага тартылган, бала тәрбияләү хокукыннан мәхрүм ителгәннәре дә шактый. Комсомол районының балигъ булмаганнар белән эшләү инспекторы Р.Бәдретдинов әйтүенчә, "Баланы ник кыйнадыгыз?" - дигән сорауга каршы кайбер өлкәннәр бернинди үкенүсез: "Без кыйнамыйбыз, ә тәрбиялибез генә", - дип җавап бирәләр.

Оператив мәгълүматларга караганда, ел саен(!) бөтен Россия буенча ундүрт яшькә кадәр булган 2 млн.га якын үсмер ата-анасы тарафыннан тукмала икән. Шуларның 10% (200 мең бала) өчен бу үлем очрагы белән тәмамлана. Ата-аналарының мыскыл итүләренә, газаплауларына түзә алмыйча 50 меңнән артык бала өйдән качарга мәҗбүр була. Ә югалган балалар турында әйтеп торасы да юк инде. Әлеге югалуларда да күп очракта өлкәннәр гаепле. Чөнки алар баланың шәхси тормышы белән аз кызыксыналар, аның кем белән аралашканын, кайда һәм нишләп йөргәнен тәгаен гына әйтә дә алмыйлар. Моның шулай икәнлеген исбатлау өчен Красноярск өлкәсендә булган фаҗигане генә искә алу да җитә. Уйлап кына карагыз әле, берьюлы биш үсмер юкка чыга. Аларны эзләүгә шул өлкәнең бөтен Эчке эшләр идарәсе күтәрелә. Малайларны өзлексез эзләүләр уңай нәтиҗә бирми. Бу очрак буенча тикшерү эше кузгатыла. Үсмерләрне шактый вакытлар узгач урманнан табалар. Дөресрәге, аларның сөякләрен, калдыкларын. Узган ел да шул ук Красноярскта тагын бер малай югала. Аның үле гәүдәсен алты тәүлектән соң бер чокырдан табып алалар. Быел исә күптән түгел әлеге шәһәрдә биш яшьлек кызчыкның вакытсыз гомере өзелүе турындагы хәбәр күпләрне тетрәндерде. Кызчыкны башта мәсхәрәләп, аннары вәхшиләрчә үтерүчене эзләү эшләре бара.

Кызганычка каршы, әллә кая ерак китәсе түгел, Чаллы шәһәре дә балалар үлеме буенча башкаларыннан калышмый. Узган елның сентябрь аенда Биклән авылында яшәүче сигез яшьлек Вероника Кәримованың югалуы турындагы хәбәр яшен тизлегендә янәшә–тирәдәге авыл һәм шәһәрләргә тарала. Аның югалуы турында телевидение һәм газеталар аша да кат-кат хәбәр итеп торалар. Озак эзли торгач, югалган кызчыкның үле гәүдәсе һәм аны үтерүче дә табыла. Вероника үги анасы үтергән булып чыга. Вероника югалып күпмедер вакыт узгач, шәһәребездә Радик исемле үсмер югала. Озакламый ул да үле килеш табыла. Тагын шуңа охшаш кайбер очраклар теркәлә. Шуңа күрә балигъ булмаганнар белән эшләү инспекторлары мәктәпләргә, өйләргә йөреп балалар һәм аларның ата-аналарына аңлату эшләре алып баралар. Өлкәннәргә балага карата бик игътибарлы булырга, аны ялгызын гына таныш булмаган урыннарга җибәрмәскә, кем белән аралашуын даими тикшереп торырга киңәш итәләр. Ә балаларны таныш булмаган кешеләр янына бармаска, өлкәннәрне кисәтмичә өйдән чыгып китмәскә, әйтелгән вакытта кайтырга, бераз тоткарланса бу турыда аларга хәбәр итәргә, билгесез машиналарга утырмаска, берәр четерекле мәсьәлә килеп чыкса өлкәннәргә әйтергә һәм һәрвакыт сак булырга кирәк дип кисәтәләр.

...Шәһәребездә гарип, акылга зәгыйфь балалар да шактый. Андыйларны тәрбияләгәндә сабырлык һәм зур җаваплылык сорала. Күп кенә ата-аналар шул җаваплылыктан, мәшәкатьтән куркып газиз балаларыннан баш тарталар. Әйе, нәкъ менә мәшәкать, авыр йөк итеп карый алар авыру балага. Аларның авыру бала тәрбияләргә теләкләре дә, вакытлары да юк. Шуңа күрә, аны бала тудыру йортында ук калдырып чыгалар. Юкса, аның гарип тууына да бары тик ата-ана гына гаепле бит. Кызганычка каршы, кайбер аналар карыннарында бала йөртеп тә тәмәке тартуны, спиртлы эчемлек яки наркотик матдә куллануны ташламыйлар. Ә ташландык нарасыйга нишләргә? Ата-анасының хатасы, ялгышы өчен ул бәхетсез язмышы белән җавап бирә. Балалар йортында, реабилитация үзәгендә дә аны колач җәеп көтеп тормыйлар, чөнки урын юк. Балалар йорты андыйлар белән шыплап тулган. Ә яңаларын ачарга уйлаган кеше юк. Киресенчә, булганы да ябыла бара әле. Аның урынына шәһәребездә дәү-дәү кибетләр, күңел ачу, ял итү үзәкләре ачыла. Бай эшмәкәрләр дә үзләренә файда, табыш китерә торган биналар гына төзетәләр. Ә ятим, мохтаҗлык кичергән сабыйларда эшләре юк аларның. Бу язманы хакимияттә эшләгән берәр түрә укыса: "Нәрсә язган булалар инде?! Реабилитация үзәкләренә, ятимнәр йортларына, күп балалы гаиләләргә фәлән миллион сум акча тотабыз!" дип отчет кәгазьләрен актара башлар. Бәхәсләшмибез. Ярдәме дә күрсәтелә. Әмма ярдәм алганнар, игътибар үзәгендә булганнар, "Хәйрия елы"ннан файда күргәннәр – айсбергның судан күренеп торган очы гына! Күренмәгән өлеше бик зур әле – яклауга мохтаҗ балалар да иксез–чиксез!

...Яшереп тормыйм, бу мәкаләмне язу кыен булды, темасы авыр: бөтенесе белгән һәм шул ук вакытта бөтенесе дә кул селтәгән нәрсәләр. Балаларга кагылышлы аяныч хәлләр җанны өшетә. Фикер эзлеклелеген, тәртибен дә саклый алмадым, бугай. Нишлисең, балаларны яклау, аларны бәхетле итү мәсьәләсендә илдә–җәмгыятьтә дә хаос–тәртипсезлек хөкем сөрә бит. Шул безнең күңелләрдә–фикерләрдә чагыла. Кыскасы шул: балалар безнең илдә тиешенчә якланмыйлар әле, алар чын яклау көтә!

Фирүзә ВӘЛИТОВА.

Ташланган бала

Ятимнәр йортына кердем,–
Күзем төште балага:
Караватына ябышып
Карап тора ул миңа.

Тәрәзәдән кояш төшә:
Бала күзләрен уа.
Кояш нуры, әниседәй,
Күренә дә, югала.

Нигә югалдың соң кояш?!
Әнисе, ник югалдың?!
Шуны уйлап күзләремнән
Ачы яшьләрем тамды...

Әниле ятим баладан
Кояш та оялгандыр.
Бу хәлләрне күрмим диеп,
Тизрәк югалгандыр...

Мин дә озак түзалмадым
Йөрәгем әрнүенә.
Кычкырасы килде шунда:
"Әниләр, җитте сезгә!"

Ярдәм итеп булса иде
Бу нәни балаларга.
Бары да җитеш, тик җитмидер
Ана назы аларга.

Ташландык түгел сабыйлар–
Алар җылы кулларда.
Берзаман дөньяны басар
Ташландык аналар да...

Рәйлә ЗАҺРЕТДИНОВА,
24нче мәктәп, 7 "А"сыйныфы.

Бәхеткә хакыбыз бар

Еллар көннән–көн яхшыра бара. Матур киенәбез, тәмле ашыйбыз, матур–матур автобусларда утырып йөрибез. Шуңа да карамастан, "замана авыр", дип күп аналар үз балаларын ташлап калдыралар яисә ятимнәр йортына илтәләр. Ятим сүзен ишетүгә дә йөрәк әллә нишләп китә. Әти–әнисе үлеп ятимнәр йортына эләгү бер хәл, әти–әнисе исән була торып ятим исемен йөртүчеләр күп хәзер. Аларның өс–башы фәкыйрь, ашаулары начар. Мин быел кызлар белән, класс җитәкчем белән ятимнәр йортына бардым. Аларны күреп йөрәгем әрнеде. Ап–ак йөзле, кечкенә балаларны күргәч елыйсым килә башлады. Без аларга уенчыклар, китаплар, киемнәр алып бардык. Балалар безнең уенчыкларга сөенделәр. Тәрбияче апалары безне тагын чакырып калдылар.

Минем балачагым бик бәхетле. Якты, җылы өйдә яшим. Ни ашасаң, ни теләсәң шул бар. Кич белән, әти–әни эштән кайткач, өй эче тагын да яктырак, нурлырак сыман.

Мин дөньядагы бөтен балаларның үз гаиләсендә бәхетле яшәүләрен телим. Чөнки һәркемнең дә бәхеткә хакы бар.

Зөһрә ШӘРАПОВА,
24нче мәктәп, 7 "Г" сыйныфы.

Әкиятне үзебез язабыз

«Борын-борын заманда...»

дип, Саба районы, Миңгәр башлангыч мәктәбенең 3нче сыйныф укучылары әрҗаңа әкиятләр уйлап чыгарганнар.

Куркак песи

...Яшәгән, ди, бер песи. Ул үзен бик горур тоткан һәм «Мин батыр !»- дип, мактанып йөри икән. Имеш, ул бер хайваннан да курыкмый. Көннәрдән бер көнне моны ишетеп, этнең бик ачуы килгән. Аны ничек булса да куркыту турында уйлый башлаган. Эт, тычкан белән килешеп, песине куркыту турында хәйлә кора. Песи әйбәт кенә урын өстендә ятканда, тычкан аның янына килеп койрыгын тешли. Бу хәлдән песи куркып китә. Ул йөгереп урамга чыга, ә алдында горур кыяфәт белән эт тора. Менә эт белән тычкан икәүләшеп көлә башлыйлар. Песи бу хәлгә бик нык хурлана. Шулай итеп, әле дә булса тычканнан куркып, тычкан тотмаган песиләр бар.

Искәндәр ЗАҺИДУЛЛИН.

Помидорлар ник кызара?

...Бер бакчада бик күп яшелчәләр үскән. Алар арасында помидор, кыяр, кишер һәм чөгендер булган. Ул заманда помидор яшел булган, ди. Җитмәсә, әле ул бик мактанчык та булган икән. «Карагыз! Мин нинди матур! Мин нинди түгәрәк!»-дияргә яраткан ул. Күршедә генә үскән кишер белән чөгендер аның мактанганын тыныч кына тыңлап торалар да, елмаеп куялар, ди.

Менә көз җитә. Яшелчәләрне җыяр вакыт та җитә. Ә помидор һаман яшел һәм тәмсез икән. Кешеләр кыярны, чөгендерне, кишерне салатлар ясар өчен, ашлар пешерер өчен җыеп бетергәннәр, ди. Яшел помидор нәрсә эшләргә дә белми икән. Тирә-юньгә карый, бер яшелчә дә күренми. Күтәрелеп караса, кояш аннан көлепме-көлә, ди. Помидор оятыннан кып-кызыл булган. Шул вакыйгадан соң помидорлар, кояштан оялып, кызара торган булып калганнар.

Алсу ХӨСӘЕНОВА.

Явыз бүре

...Яшәгән, ди, бабай белән әби. Боларның бер кызлары булган. Кыз җиләк җыярга дип, урманга китә. Каршысына бер бүре килеп чыга. Бүре әйтә кызга: «Син нишлисең?». Кыз аңа: «Җиләк җыям»,- дип җавап бирә. Бүре: «Әйдә, мин сиңа булышам»,- ди. Кыз риза була. Менә кызның кәрзине тула. Кыз кайтырга чыга, ә бүре аның артыннан. Кызны ул шулай өенә кадәр озатып куя. Ә кыз аңа рәхмәтләр әйтеп, саубуллаша. Кич җитеп, караңгы төшкәч, бүре кызларның келәтенә килә һәм бер әтәчне алып кача. Бабай кереп караса, бер әтәч юк. Икенче көнне бабай әтәчне эзләргә урманга китә. Эзли-эзли, әтәч бер җирдә юк. Тагын да эчкәрәк керсә, әтәч тавышы ишетелә. Бабай барып караса, бүре әтәчне чак кына ашамаган. Бүре, кулына зур мылтык тоткан бабайны күреп, чак качып котыла, ә бабай әтәчне өенә алып кайтып китә.

Эльмира ЗАКАРОВА.

Хәйләкәр куян

...Яшәгән, ди,бер куян. Көннәрдән бер көнне урманга, йөреп кайтырга дип чыгып киткән. Ул анда бүрене күреп алган. Ул вакытта бүреләр һәм куяннар үзара дус булганнар, ди. Ләкин бүре ачлыкка түзә алмаган һәм әйткән: «Куян, хәзер мин сине ашыйм!»- дигән. Куян куркып калган, әмма телгә килеп болай дигән: «Тукта, мине ашаганчы бер сүз әйтимче сиңа: минем белән генә синең тамагың туймаячак бит. Бүген кое янына кил, мин сиңа үземнең дусларымны алып килермен». Килә бүре кое янына. Анда аны куянкай каршы ала. Куян әйтә бүрегә: «Минем дусларым коега су эчәргә төшеп киттеләр.» Бүре ач булгач, нишләсен, коега үзе сикергән. Ә куян тиз генә коеның капкачын каплап та куйган. Бу турыда башка бүреләр дә ишеткән. Шушы көннән башлап, бүреләр һәм куяннар арасындагы дуслыкка нокта куелган.

.Ландыш ЗАҺИРОВА.

Аю баласы

...Яшәгән, ди, бер кечкенә генә аю баласы. Ул бик тәртипле, акыллы булган, әти-әнисенең сүзен тыңлаган, ди.

Бервакыт аю баласы ялгызы гына урманга җиләк җыярга киткән. Чиләге тулгач, кайтыр юлга чыккан, ләкин юлны таба алмаган. Ул урманда бик тә курыккан, елаган. Менә караңгы да төшеп килә икән. Шулвакыт куаклар арасыннан куян килеп чыккан. Куян: «Ник елыйсың?» - дигән. «Җиләк җыярга чыккан идем, адаштым»,- дигән аю баласы. «Әйдә, бергә киттек. Мин синең әниеңне күрдем, алар сине эзләп йөриләр иде»,- дигән аңа куян.

Өйләренә кайткач, аюның әнисе куянны бик мактаган һәм күп итеп кишер биреп җибәргән. Куян белән аю баласы бик дус булып калганнар.

Азат СӨЛӘЙМАНОВ.

Белдерү

Ял итәргә килегез!

Безнең Чаллы шәһәрендә инде җиденче ел рәттән татар балалары өчен "Мизгел" дип исемләнгән милли-мәдәни лагерь оештырыла. Биредә ял итүче балалар саф һавада, ямьле табигать кочагында ял итү белән беррәттән, телебезне, мәдәниятебезне һәм татар халкына хас күркәм гадәт-йолаларны өйрәнәләр. Гыйлем сәгатьләре, татар дискотекалары, сәнгать дәресләре, "Татар егете", "Татар кызы" бәйгеләре, Чаллы татар драма театры куйган спектакльләр, экскурсияләр - барысы да балаларда үз милләтебез белән горурлык хисен тудыру һәм үстерү ниятеннән оештырыла. Лагерьда республиканың төрле шәһәр-районнарыннан һәм Башкортстаннан килгән, 9 яшьтән 14 яшькә кадәрге балалар ял итә. Быел лагерь үзенең эшчәнлеген 3 июньдә башлап җибәрәчәк. Ял итәргә, яңа дуслар табарга теләгән балалар "Нур" яшьләр үзәгенә (Яңа шәһәр, 1/02) килеп яки **39-67-99** телефонына шалтыратып, "Мизгел" лагерена языла алалар.

Без сезне көтәбез, балалар!

Көмеш кыңгырау

"Көмеш кыңгырау"ны гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы.

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

Рәссам -
Фаил Ислам

Язмаларны компьютерда җыючы һәм урнаштыручы-
Эльвира Салихова
Ләйлә Абдуллина

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде

"Көмеш кыңгырау" газетасы массакүләм мәгълүмат чаралары һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендәге законнарны үтәүгә күзәтчелек итүче федераль хезмәтенең Идел буе идарәсендә ПИ №ФС7-3729 саны белән теркәлде.

БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ, ХАТЛАР ЯЗЫГЫЗ:
423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Гидротөзүчеләр урамы, 10нчы йорт, 429нчы бүлмә. "Көмеш кыңгырау" газетасы редакциясе.
E-mail:komesh_k@List.ru

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:

71-50-22 *- баш мөхәррир.*
71-49-94 *- операторлар, тәрҗемәче.*
71-50-24 *- баш хисапчы, баш мөхәррир урынбасары, рәссам.*

Редакциягә килгән хатлар рецензияләнми, кире кайтарылмый.

"Көмеш кыңгырау"дан алынган язмаларның чыганагын күрсәтү мәҗбүри.

р/с 40703810810000000449 в ЗАО ГКБ "Автоград-банк" г.Н.Челны к/с 30101810100000000748 БИК 049240748. ИНН 1650048918

Җаваплылыгы чикләнгән "Глагол" ширкәте типографиясендә басылды. Язмаларның эчтәлеге һәм аларны газетада урнаштыруның сыйфаты өчен типография җавап бирми.

Атнага ике тапкыр чыга.
Индекс 31700
"Көмеш кыңгырау" тиражы - 4000

Басарга кул куелды 29.05.2007

© "Көмеш кыңгырау", 2007 ел